КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 18 май г.Казань № 401

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 25 апрель, 327 нче карары белән расланган Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 25 апрель, 327 нче карары белән расланган Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 нче пунктның җиденче абзацында «кереме заявка биргән айга кадәрге айга 2019 елның уртача айлык кереме белән чагыштырганда 30 проценттан күбрәк кимегән» сүзләрен «исәп-хисап счетлары буенча әйләнешләре заявка биргән айга

кадәрге айга 2019 елның исәп-хисап счетлары буенча уртача айлык әйләнешләр 30 проценттан күбрәк кимегән» сүзләренә алыштырырга;

3.1 нче пунктта:

тугызынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«оешманың исәп-хисап счеты номеры, исеме һәм әйләнешләр суммасы турындагы мәгълүмат белән кредит оешмаларының 2019 елның 1 гыйнварыннан 2019 елның 31 декабренә кадәр исәп-хисап счетлары буенча айлык әйләнешләр хакында белешмәләре;

оешманың исәп-хисап счеты номеры, исеме һәм әйләнешләр суммасы турындагы мәгълүмат белән кредит оешмаларының заявка биргән айга кадәрге айга исәп-хисап счетлары буенча әйләнешләр хакында белешмәләре;»;

бу Тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин